ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 декабрь 2024ел № 8116

Башкарма комитетның 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карары белән расланган 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2595 номерлы, 2023 елның 16 ноябрендәге 11212 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1006 номерлы, 2024 елның 4 апрелендәге 2155 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 5454 номерлы, 2024 елның 9 октябрендәге 6582 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «10. | Татарстан Республикасы һәм Яр Чаллы шәһәре үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны, Мактаулы гражданнарны җирләү чарасы | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | Ел дәвамында | Кеше саны | 1 | 2 | 2 | 2 | 160,00 | 310,00 | 160,00»; |

2) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «12. | Бөек Ватан сугышы ветераннарын, хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, беренче төзүче-ветераннарны календарь бәйрәмнәр белән (23 февраль, 8 Март, 9 Май), шәһәр һәм республика үсешенә зур өлеш керткән юбилярларны (90, 95, 100 яшь һәм өлкәнрәк) котлау | Башкарма комитет | Ел дәвамында | Кеше саны | 0 | 300 | 300 | 300 | 192,00 | 415,97 | 565,97». |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов